Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлеге Түбән Әлки авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 21 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 17 номерлы Әлки муниципаль районының «Түбән Әлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районыТүбән Әлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 16 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» турындагы карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлегенең Түбән Әлки авылында 2019 елның 21 ноябрендәге 7 номерлы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге составына керүче Түбән Әлки авылындагы гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

алардан:

- Түбән Әлки авыл җирлегенә кергән торак пунктларда авыл эчендәге юлларны карап тоту (җир, ком, вак таш, сибү; торак пунктлар эчендәге юл кырыйларын чабу, грейдерлау юлларны кардан чистарту) – 215 сум;
- төзелеш, су белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны һәм су челтәрләрен реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкару, су белән тәэмин итүнең урам системасын ремонтлау, су башнялары территорияләрен коймалау һәм буяу һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү-150 сум;
- урамнарны яктырту өчен кулланылган энергия чыгымнарын түләү, янган җиһазларны алыштыру өчен кирәкле материал сатып алу һәм электрик өчен түләү-150 сум;

-чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу, белгечләргә түләү-85 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**3.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

- Түбән Әлки авыл җирлегенә кергән торак пунктларда авыл эчендәге юлларны карап тоту (җир, ком, вак таш, сибү; торак пунктлар эчендәге юл кырыйларын чабу, грейдерлау юлларны кардан чистарту) – 215 сум;
- төзелеш, су белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны һәм су челтәрләрен реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкару, су белән тәэмин итүнең урам системасын ремонтлау, су башнялары территорияләрен коймалау һәм буяу һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү-150 сум;
- урамнарны яктырту өчен кулланылган энергия чыгымнарын түләү, янган җиһазларны алыштыру өчен кирәкле материал сатып алу һәм электрик өчен түләү-150 сум;

-чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу, белгечләргә түләү-85 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Түбән Әлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлеге башлыгы: М. Р. Галиуллин